**ГЛАВА ЯМАШУРМИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ВЫСОКОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
422735, Республика Татарстан, Высокогорский район,,
с.Ямашурма, ул. Советская, 5

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ЯМАШИРМЭ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ**
422735, Татарстан Республикасы, Биектау районы,
Ямаширмэ авылы, Совет ур.,5

Тел./факс: +7(84365) 777-02, e-mail: Yamash.Vsg@tatar.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**
**30 октябрь 2024 ел** **№ 13**

# Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Ямаширмә авыл җирлегенең Ямаширмә торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының Ямаширмә авыл җирлеге Уставының 22 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының Ямаширмә авыл җирлеге муниципаль берәмлеге башлыгы

Карар кылды:

1. Биектау муниципаль районы Ямаширмә авыл җирлегенең Ямаширмә авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар Җыенының беренче этабын 2024 елның 22 ноябрендә 11 сәгать 00 минутка билгеләргә.

2. Биектау муниципаль районы Ямаширмә авыл җирлегенең Ямаширмә авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар Җыенының икенче этабын 2024 елның 22 ноябрендә 14 сәгать 00 минутка билгеләргә.

3. Биектау муниципаль районы Ямаширмә авыл җирлегенең Ямаширмә авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар Җыенының өченче этабын 2024 елның 22 ноябрендә 16 сәгать 00 минутка билгеләргә.

4. Гражданнар җыенын уздыру өчен Ямаширмә авылында яшәүчеләр Исемлеге территориаль билге буенча бүленгән:

а) беренче этап-Гагарин, 1 Май, Яңа, Яшел, Ленин, Марс урамнарында яшәүчеләр;

б) икенче этап-Вахитов, каен, Ключевая, М. Җәлил, Татарстан урамнарында яшәүчеләр

в) өченче этап-Полевая, Молодежная, Тукай, Нариманов, Совет, Мәктәп, Киров, Крайняя урамнарында яшәүчеләр;

5. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Ямаширмә авыл җирлегенең Ямаширмә авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән 2025 елда 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә ризамы Сез, СВО да катнашучы халыктан, аларның бергә яшәүче гаилә әгъзаларыннан, 1 төркем инвалидлардан, тыл хезмәтчәннәреннән, тол хатыннардан, яткан авырулардан тыш алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү:

1) су белән тәэмин итү һәм ташу системаларын, су җыю манараларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортировкалауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итә торган башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау;

2) тротуарларны төзү, ремонтлау;

3) торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмиятле автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту,

4) торак пункт территориясен төзекләндерү.

“ӘЙЕ” "КАРШЫ" ӨЧЕН.

6. Әлеге карарны Биектау муниципаль районының Интернет челтәрендәге рәсми сайтында түбәндәге веб-адрес буенча карарны халыкка җиткерергә: http://vysokaya-gora.tatarstan.ru/ һәм Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында: http://pravo.tatarstan.ru.

7. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Совет Рәисе

Авыл җирлеге башлыгы Ф. К. Мохтаров